Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 56 01.12.2025 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 01 мартындагы 9 номерлы карары (2022 елның 02 сентябрендәге 29 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 39 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 01 мартындагы 9 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 п.4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк»сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5 бүлегенең 2.5.1 п. 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 4_1 пунктчасы өстәргә:

«4_1) Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләп ителми;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм httr хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.Т.Галяутдинова.